




# Дәүләт йомгаклау аттестациясенә әзерлек вакытында ата-аналарның балаларга психологик ярдәме

# БОРЧЫЛУЧАН БАЛАЛАР

Бу очракта уку процессы билгеле бер эмоциональ киеренкелек белән бәйле. Балалар уку белән бәйле ситуацияне, үзләре өчен куркыныч итеп кабул итәләр. Бигрәк тә аларны контроль эшләр, диктант һ. б. язма эшләр борчуга сала. Мондый балалар эшләнгән эшләрен кат-кат тикшерәләр, язганнарын төзәтәләр. Бу күп очракта хаталар ясауга китерә. Телдән җавап биргәндә алар өлкәннәрнең реакциясенә карыйлар, бик күп сорау бирәләр. Мондый балалар ручкаларын кимерәләр, бармаклары белән чәчләрен тарыйлар. Имтихан вакытында алар өчен иң авыры – өлкәннәр белән эмоциональ бәйләнеш булмау. Шуңа күрә әзерлек вакытында аларга эмоциональ уңайлыклар, үз-үзенә ышаныч тудырырга кирәк. Балаларыгыз һәрвакытта да сезнең терсәгегезне тоеп торсыннар.

# ҮЗ-ҮЗЛӘРЕНӘ ЫШАНМАУЧЫ БАЛАЛАР

Мондый баланың иң зур проблемасы – үз-үзенең белеменә ышанмау. Ул үзлектән эшенең сыйфатын тикшерә алмый. Алар бары тик үрнәк буенча яхшы эшли, үзлектән эшләгәндә – иптәшләренә, ата-аналарына (өй эшен эшләгәндә) мөрәҗәгать итәләр. Мондый балалар белемнәре булмаудан түгел, ә үз-үзенә ышанмау аркасында кӱчерәләр. Имтихан вакытында алар мөстәкыйль рәвештә карар чыгарырга куркалар. Әзерлек вакытында бу балаларга киңәш бирүдән тыелып калырга, ничек булса да аларда үз-үзләренә ышаныч тудыру ягын карарга кирәк.

# ИГЪТИБАРСЫЗ, ТАРКАУ БАЛАЛАР

Алар белемсез түгел, ләкин бирелгән вакытны рациональ файдалана алмыйлар. Мондый балаларның эшен оештырган вакытта төрле материаль чыганаклар кулланырга була. Мәсәлән, биремне эшләргә бирелгән вакытны контрольдә тоту өчен ком сәгате файдалану яки эшләнәсе эшләрнең исемлеген булдыру һәм эшләгән һәр эшне сызып бару.

# ОТЛИЧНИКЛАР

Аларның белемнәре ныклы, һәр эшкә җаваплы карыйлар. Әгәр дә инде нинди дә булса эшкә алынсалар, бу балалар аны җиренә җиткереп эшлиләр, өстәмә мәгълүмат та җыерга мөмкиннәр. Аларга бөтен эшне дә яхшы, бик яхшы үтәргә, мактау сүзләре ишетергә кирәк. Имтихан вакытында мондый балалар өчен "Иң яхшы – яхшының дошманы" булырга мөмкин. Шуңа күрә аларга әзерлек вакытында "бик яхшы" эшләү белән "җитәрлек" эшләү арасындагы аерымлыкны аңлатырга кирәк.

# ТИЗ АРУЧАН БАЛАЛАР

Мондый балалар  тиз арулары аркасында бик күп хата җибәрәләр. Бу аларның югары нерв эшчәнлеге үзенчәлеге белән бәйле. Аларга эш арасында ял итәргә, җитәрлек йокларга  кирәк. Аларны ашыктырырга ярамый. Мондый балалары булган ата-аналарга психоневролог, невропотолог белән киңәшсәләр, яхшы булыр.

# Нәрсәгә билге куела?

***Фактик белемнәр генә түгел, аларны күрсә-тә белү дә мөһим. Сөйләм теле бай булу, белемдәге кимчелекләр не яшерергә ярдәм***

***Фикерләүгә, биремне аңлап эш итүгә, үз эшеңне планлашты-ра, оештыра белүгә нигезләнгән***

# Билгегә нәрсә тәэсир итәргә мөмкин?

Субъектив факторлар җыелмасы: имтихан алучы белән контакт, гомуми фикер һ. б.

Билге максималь объектив

# Үз хатаңны төзәтү мөмкинлеге

***Традицион, телдән имтихан вакытында хатаны сөйләгәндә, имтихан алучыга ка-рап***

***Хаталарны үзең генә тикшереп , төзәтергә була.***

# Кем билге куя?

*Таныш кешеләр.*

*Компьютер, таныш булмаган кешеләр, без аларның эшләрне ничек тикшергәннәре*

# Имтихан нәтиҗәләрен кайчан белеп була?

*Телдән имтиханның нәтиҗәсен шул ук көндә, язмачаныкын – берничә көн*

*Берничә көн дәвамында.*

# Имтихан эчтәлеге

*Укучы белемен билгеле бер темага, сорауга җавап биреп күрсәтә.*

*Имтихан материалының бөтен бүлеге буенча алына.*

# Нәтиҗәләрне теркәү

***Язмача имтиханны аерым бирелгән биттә, телдән - караламада.***

***Биремнәрне эшләү нәтиҗәләрен махсус бланкка тутырырга кирәк.***